**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Иштирәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«22» ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Тукай муниципаль районының« Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 52/1 номерлы карары түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк урамындагы юлны ремонтлау)
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычлары, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру);

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы <u>393</u> кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – <u>206</u> кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы <u>203</u> кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы <u>0</u> кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштрәк авыл җирлеге Иштирәк авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә, аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк урамындагы юлны ремонтлау)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны реконструкцияләү, урам яктырткычлары, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру).

3. Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Иштирәк авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы А.П. Васильева